**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Учаллинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д. 51 , село Учалле,
Азнакаевского муниципального района, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге**

**БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423317
Тел. (факс) (85592) 36-8-32
Uchal .Azn @tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2022ел. №5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә: Совет урамы буенча 1 йорттан 83 йортка кадәр, Октябрь урамы буенча 1 йорттан 17 йортка кадәр, Комсомол урамы буенча 1 йорттан 8 йортка кадәр, Яшьләр урамы буенча 1 йорттан 9 йортка кадәр, Тукай урамы буенча 1 йорттан 23 йортка кадәр;

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын уздыру вакыты-2022 елның 15 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенын үткәрү урыны- Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт, Үчәлле авылы мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 2 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу

хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 йорты;

- сайлау хокукына ия булган Үчәлле торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

-Үчәлле торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Үчәлле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары (тракторчы белән техниканы арендалау, килешү буенча хезмәт өчен түләү, сыешлыкны арендалау, янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм тоту);

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне» бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Үчәлле авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- Үчәлле авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш юлларын профильләштерү);

-Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне чабу, территорияләрне кипкән агачлардан һәм куаклардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәт күрсәтүе)

ӘЙЕ КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә;

-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

-Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина